***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Гомеремдә беренче тапкыр авылымны ташлап чыгуымны сөйлим әле. Җәйнең бик матур бер көнендә Хәлимә апа мине үзләренең авылына кунакка алып китте. Минем улым синең белән яшьтәш, аның гармуны да, велосипеды да бар, икәүләп уйнарсыз, дип кызыктыргач, мин дә, әнкәй дә ризалаштык.

Аларның авылы бездән җиде чакрымда. Малайлары минем кебек бишлегә генә укуы өстенә, тальян гармунда сыздырып уйнавы белән шаккаттырды, мине дә өйрәтергә сүз бирде. Өйләре дә зур, бай җиһазлы, ни ашасаң, шул бар. Ләкин нишләптер кичкә таба мин кызык тапмый башладым, күңелемә әллә нинди сагынуга тартым бер нәрсә кереп оялады, күңелем төште.

Кинәт ай чыкты. Шунда миңа әллә ни булды, бу безнең авыл ае түгел иде! Ул, нишләптер, бик тә кызганыч иде, минем күзләремә яшьләр килде....

Төнлә мин юньләп йоклый алмадым. Иртән ашап-эчкәч тә, Олы Чакмакка кайтам, дидем. Минем бу сүзләрем аларны шаккаттырды, бөтенесе беравыздан: "Тагын бер генә көн!" – дип кыстарга тотынды. Мин чак кына елап җибәрмәдем. Әгәр бер көнгә калсам, Олы Чакмагыбыз, әнкәй, күршеләр, дус малайлар, Ык буйлары, болын-әрәмәләр, тагын әллә нәрсәләр юкка чыгар кебек. Үгетләүләренә карамастан, кайтып киттем. Башта йөгерә-атлый бардым, авылны чыккач, тузанлы юлдан тондым гына!

Йә, Хода, әнә бит авыл шунда – урынында! Әнә бит Гыймай тавы битләре, безнең урам башындагы өйләр, су суырта торган биек тимер колонканың түгәрәк ясап әйләнә торган матур канатлары! Шатлыктан күзләремә яшь тула, мин аларны сөртмим дә, юньләп тоймыйм да. Мин ничек бәхетле идем бу минутларда! Мондый шатлыкны тагын ничә мәртәбә кичердем икән мин үз гомеремдә?! Бөтен йөзләрем, тәннәрем ут булып янган, йөрәгем ашкынып типкән хәлдә юлдагы тузаннарга, читтәге үләннәргә басып, әллә очып, авылга кайтып җитәм.

Мин урам капкасын ачып керәм, тыным кабып ишек янына киләм, бүрәнә башыннан ачкычны алам. Сәке өстендәге киезгә мендәр салам да шунда авам.

*(Ф. Садриев)* (276 сүз)

***Чыганак:** Ф. Садриев. Авылдан хатлар. – Казан, 2009. – Б.5-6.* **Фоат Садриев** (1941) – танылган язучы-прозаик, драматург, журналист, Г. Тукай бүләге иясе.

